СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«11» июль, 2024 ел Алабуга шәһәре № 363

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 декабрендәге 134 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 134 номерлы карары белән расланган, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче бүлекнең 3.2 пунктындагы 3.2.24 пунктчасының 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.24. Җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру.».

1.2. 3 нче бүлекнең 3.2 пунктындагы 3.2.29 пунктчасының 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру.».

1.3. 3 нче бүлекнең 3.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге редакциядә 3.2.36 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.2.36. Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләр гә карата мондый зыянны бетерү.».

1.4. 3 нче бүлекнең 3.2 пунктындагы 3.2.30 пунктчасының 1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.30. Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иректе үтеп керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү.».

2. Әлеге карарның 1.1 пунктында каралган нигезләмәләр 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе Р.М. Нуриев